# ***КӨЗ***

***Күңелләргә сагыш салып,***
***Көзләр дә җиткән икән.***
***Куе урман өсләреннән***
***Сарысын сибеп үткән.***
***Пәрәвез җепләреннән ул***
***Үреп куйган ятьмәсен.***
***Чү! Кузгатма син аны, җил,***
***Бу матурлык бетмәсен.***
***Сары яфрак кулын изәп,***
***Алтын көз саубуллаша.***
***Үрелеп, нур сибә кояш***
***Болыт ертыгы аша.***
***Шушы нурлардан тулышып,***
***Тагын ямь иңә җиргә.***
***Сагыш түгел, муллык тула***
***Алтын көз белән бергә.***
***Күңелгә көзге муллыктан***
***Бәхет, шатлык тула сыман.***
***Ил-көненә өмет баглап,***
***Киләчәккә атлый җиһан.***

Суфия Мостафина

# КӨЗГЕ СЫНАМЫШЛАР

**Көз озын килсә, яз соң килер.**

**Көз көне куяннар бер эздән йөрсәләр, кыш көне кар күп булыр.**

**Көзнең ахырында вак кына түгәрәк-түгәрәк боз яуса, кыш суык булыр.**

**Әгәр кар көзен озак ятмаса, ашлык начар булыр.**

**Көзге көн бәс тотса, аязлыкка галәмәт .**

**Бозлар көз көне шадра булып катса, ашлык яхшы булыр.**

**Көздән иртә кар яумаса, алгы җәйне иген уңышы начар булыр.**

**Әгәр кар җиде мәртәбә явып, җиде мәртәбә эреп бетеп, сигезенче мәртәбәдә төшсә, киләсе җәйне ашлык бик яхшы булыр.**

**Көзге көн бәс тотса, аязлыкка галәмәт.**

**Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә.**

**Суганның кабыгы ике кат булган елны кыш җылы булыр, ә кабыгы күпкатлы булган елны кыш салкын булыр.**

**Урманда чикләвек күп булса, кыш кырыс булачак.**

**Чия яфраклары коелып бетми торып, кар, күпме яуса да, барыбер эреп бетә.**

**Көз көне каен агачлары астан саргаеп, яфракларын астан коя башласалар – кыш җылы килә, ә өстән саргаеп, өстән яфрак коя башласалар – кыш салкын килә.**

**Кыр казлары иртә китсә, кыш иртә килә.**

**Кыр казлары көзен киткәндә түбәннән очып китсәләр, кар тиз булыр.**

# КӨЗ ТУРЫНДА ТАБЫШМАКЛАР

**Хәр көн диярлек**

**Елап яшь коя.**

**Килгән кошларны**

**Көньякка куа.**

**Бу кайсы вакыт? *( Көз)***

**Күктәнкилде,җиргәкитте. (Яңгыр)**

**Аяксыз-кулсыз дөп-дөп кое казый. *(Тамчы)***

**Яз килсә – киенә,**

**Көз килсә – чишенә. *(Агач)***

**Язын дөньяга килә,**

**Көзен саргаеп үлә. (*Яфрак)***

**Аяксыз, кулсыз, капка ача. *(Җил)***

**Агач бөгә – кулы юк, йөри торган юлы юк.**

**Ачуланса – сызгыра, тузаннарны туздыра.**

**(*Җил*)**

**Аягы юк, кулы юк, үзе сүрәт төшерә. (Суык)**

***Алтын көз. Үзенең җилләре-яңгырлары, салкыннары белән зур-зур адымнар атлап, көз килеп тә җитте. Яктырып кояш елмайды да, “Әбиләр чуагы” икәнен белдереп, битне пәрәвез җепләре иркәләде. Зәңгәр күктә зур ак пароходлар кебек болытлар, узыша-узыша каядыр чабалар. Җиргә түшәлгән йомшак алтын яфраклар, әйтерсең, төрек keләмнәрен хәтерләтә. Ә агачлар!? Берсен-берсе уздыра-уздыра җәйге киемнәрен көзгегә алмаштырганнар. Һәрберсе күз явын алырлык. Урталыктагы миләш агачының кып-кызыл җимешләре, ялкындай яфракларына соклану мөмкин түгел. Зифа каеннар, нәзек усаклар купшы алтынсу шәл ябынып, баһадир имән агачын кунакка көтәләрдер кебек. Ара-тирә чыпчык, карга тавышлары тирән тынлыкка җан өргәндәй була. Төз нарат агачлары гына, башларын югары күтәреп, яшеллеккә күмелеп басып торалар кебек. ”-Безгә көз куркыныч түгел”- ди алар. Чү! Кинәт көн дә бозыла бугай. Җил битне чеметеп-чеметеп алды. Шул арада куркыныч болытлар да хасил булды. Тирән итеп һава сулыйм. Көз һавасы, нинди дымлы да, салкын да син!***






